КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.11.2018 № 82

г. Казань

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясе чикләрен һәм файдалану режимын раслау турында

“Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында”гы 2002 елның 25 июнендә кабул ителгән 73-ФЗ номерлы законына, “Татарстан Республикасында мәдәни мирас объектлары турында”гы 2005 елның 1 апрелендә кабул ителгән 60-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, махсус җайга салына торган шәһәр төзелеше эшчәнлеге объектлары буларак, федераль әһәмияткә ия мәдәни мирас объектларын һәм аларның территорияләрен саклауны һәм дәүләт тарафыннан саклап тотуны тәэмин итү максатларында, боерам:

1. Бу боерыкның 1нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясе чикләрен расларга.

2. Бу боерыкның 2нче кушымтасы нигезендә, Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр

гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясеннән файдалану режимын расларга.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының «28»
11 2018 ел
№ 82
боерыгына 1нче кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия **территориясенең чикләре**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең **картасы**




Условные обозначения:

территория объекта культурного наследия

объект культурного наследия

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх.

В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең
**картографик тасвирламасы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең чикләре түбәндәгечә үтә:

**төньяк-көнчыгыш өлеш:** Карл Маркс урамы кызыл линиясе буенча җир кишәрлегенең алгы чиге буенча Япеев һәм Карл Маркс урамнары кызыл линия чигенә кадәр (1-2 борлышы нокталары);

**көньяк-көнчыгыш өлеш:** җир кишәрлегенең ян чиге буенча, 3нче борылыш ноктасына кадәр корылманың кызыл линиясе буенча, 1968 елда төзелгән 3 катлы кирпеч бина янында урнашкан җир кишәрлегенең ян чиге һәм Япеев урамының кызыл линиясе буйлап (2-3 борылыш нокталары);

**көньяк-көнбатыш өлеш:** Миславский урамындагы корылмаларның кызыл линиясендә урнашкан 9нчы ноктага кадәр ишегалды корылмалары буйлап һәм 1845 елда төзелгән 2 катлы бина почмагында (3-9 борылыш нокталары);

Миславский урамындагы бинаның кызыл иниясе буйлап, Миславский һәм Карл Маркс урамнары кисешкән урынга кадәр җир кишәрлегенең ян чиге буенча (9-1 борылыш нокталары).

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең чикләренең борылыш нокталары таблицасы

| Нокта № | Нокталарның җирле кординаталар системасындагы координаталары (МСК) | | Нокталарның җирле кординаталар системасындагы координаталары (МСК-16) | | 1984 елгы Бөтендөнья геодезик координаталар системасында нокта координаталары (WGS 84) | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | X | Y | X | Y | Төньяк киңлек B | Көнчыгыш озынлык L |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| **1** | 536,807 | -401,302 | -474157,472 | -1306420,896 | 55˚ 47′ 49.94″ | 49˚ 06′ 46.19″ |
| **2** | 512,200 | -248,020 | -474182,246 | -1306267,640 | 55˚ 47′ 49.14″ | 49˚ 06′ 54.99″ |
| **3** | 450,363 | -256,602 | -474244,074 | -1306276,289 | 55˚ 47′ 49.15″ | 49˚ 06′ 54.50″ |
| **4** | 452,445 | -272,064 | -474241,975 | -1306291,749 | 55˚ 47′ 49.21″ | 49˚ 06′ 53.61″ |
| **5** | 453,337 | -271,886 | -474241,084 | -1306291,570 | 55˚ 47′ 49.24″ | 49˚ 06′ 53.62″ |
| **6** | 457,440 | -304,772 | -474236,945 | -1306324,452 | 55˚ 47′ 49.37″ | 49˚ 06′ 51.73″ |
| **7** | 461,663 | -304,058 | -474232,722 | -1306323,733 | 55˚ 47′ 49.51″ | 49˚ 06′ 51.77″ |
| **8** | 482,536 | -403,253 | -474211,741 | -1306422,906 | 55˚ 47′ 49.19″ | 49˚ 06′ 46.08″ |
| **9** | 490,445 | -421,509 | -474203,812 | -1306441,153 | 55˚ 47′ 49.44″ | 49˚ 06′ 45.03″ |

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитетының
« 28 » 11 2018 ел
№ 82 боерыгына 2нче
кушымта

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясеннән **файдалану режимы**

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең чикләрендә түбәндәгеләр **рөхсәт ителә:**

мәдәни мирас объектының физик яктан саклануын тәэмин итүгә юнәлтелгән саклау эшләрен башкару, шул исәптән, консервацияләү, ремонтлау, реставрацияләү һәм заманча файдалануга яраклаштыру;

мәдәни мирас объектының бөтенлеген тәэмин итү таләпләренә каршы килмәгән һәм мәдәни мирас объектының бүгенге шартларда кулланылышын тәэмин итү мөмкинлеген биргән хуҗалык эшчәнлеге алып бару;

булган капиталь төзелеш объектларын, шулай ук җир биләмәләрен файдалану (капиталь төзелеш объектларын төзүдән һәм капиталь булмаган корылмадар урнаштырудан тыш);

җир биләмәсен файдалану, мәдәни мирас объектын җир биләмәсен һәм капиталь төзелеш объектларын түбәндәге рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча заманча куллануга яраклаштыру (рөхсәт ителгән файдалану төрләре кодлары Россия Федерациясе икътисади үсеш министрлыгының 2014 елның 1 нче сентябрендә кабул ителгән 540 нчы номерлы “Җир биләмәләрен фадалануның рөхсәт ителгән төрләре классификаторын раслау турынлагы” боерыгы нигезендә күрсәтелгән):

торак корылмаларга хезмәт күрсәтү (код 2.7);

социаль хезмәт күрсәтү (код 3.2);

сәламәтлек саклау (код 3.4);

белем бирү һәм мәгариф (код 3.5);

мәдәни үсеш (код 3.6);

иҗтимагый идарә (код 3.8);

эшлекле идарә (код 4.1);

кибетләр (код 4.4);

банк һәм иминият эшчәнлеге (код 4.5);

җәмәгать туклануы (код 4.6);

кунакханә хезмәте (код 4.7);

ял (рекреация) (код 5.0);

спорт (код 5.1);

тарихи-мәдән эшчәнлек (код 9.3);

мәдәни мирас объектының югалган элементларын һәм өлешләрен гамәлдәге сызымнар, үлчәмнәр һәм тарихи аналоглар буенча реставрации юлы белән тергезү (яңадан торзыгу);

мәдәни мирас объектының тулылыгын боза торган вакытла корылмаларны һәм объектларны сүтү;

башкарылучы эшләрнең (шул исәптән динамик йогынты) мәдәни мирас объектына йогынты ясамау шарты белән гамәлдәге инженер инфраструктурасы объектларын капиталь ремонтлау (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефон элемтәсе белән тәэмин итү);

территориядә мәдәни мирас объектын саклауга, файдалануга һәм популярлаштыруга юнәлтелгән төзекләндерү эшләре:

мәйданчыкларны, юл чыгу урыннарын түшәүдә традицион материаллар (таш, гранит һәм табигый материалга охшаш башка материаллар) куллану,

тарихи мохит элементлары характеристикаларына җавап бирә торган аерым урнаштырылган яктырту җайланмаларын куллану;

-  агачларның һәм куаклыкларның кыйммәтле токымнарын утырту; чәчәк түтәлләре һәм газоннар ясау;

 -   мәдәни мирас объекты фасадында мәгълүмати язулар һәм билгеләмәләрне, мемориаль такталарны мәдәни мирас объектының 1 нче катыннан югарырак күтәрмичә урнаштыру;

-   кулланучылар игътибарына оешмаларның җитештерүче (башкаручы, сатучы), җитештерү урыны (адресы) һәм эшләү вакыты турындагы мәгълүматны җиткергән элмә такталарын, 1999 нчы елның 7 нче февралендә кабул ителгән 2300-1 номерлы “Кулланучылар хокукларын яклау” турындагы Федераль законы нигезендә, мәдәни мирас объектының 1 нче катыннан югарырак күтәрмичә урнаштыру. Югарыда күрсәтелгән мәгълүмати конструкцияләрнең биеклеге фриз биеклегенең 2/3 нән һәм катлардагы тәрәзә аралары чикләре теге яки бу конструкцияне урнаштыруның регламентлаштыру кысаларына туры китереп урнаштырыла. Аркалы тәрәзәләр булган очракта бина катлары тәрәзәләре арасында урнашкан конструкцияләрнең биеклеге 2/1гә кадәр кими. Мәгълүмати конструкцияләрнең киңлеге, теге яки бу конструкцияне урнаштыруны регламентлаштыру чикләрендә каралганча, дивар киңлегенең 2/3 өлешеннән дә артык булмаска тиеш;

мәдәни мирас объекты фасадларын төнге яктырту җайланмаларын файдалану;

эшләр археология белән берлектә алып барылганда территориянең директив дәрәҗәсен түбәнәйтү, ишек алды территорияләрен вертикаль планлаштыру.

Югарыда атап үтелгән барлык эшләр Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитеты тарафыннан бирелгән язмача рөхсәт нигезендә, Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектын саклау комитеты белән килештерелгән мәдәни мирас объектларын саклап калу буенча проект документларын әзерләү һәм эшләр башкару буенча йөкләмәгә, шулай ук проект документациясенә туры китерелеп башкарыла.

Татарстан Республикасы Казан шәһәре Карл Маркс урамы, 10нчы йорт адресы буенча урнашкан «Беренче ирләр гимназиясе бинасы», 1808-1811 еллар, арх. В.А.Смирнов, Я.М.Шелковников төбәк әһәмияткә ия территориясенең чикләрендә түбәндәгеләр **тыела:**

мәдәни мирас объектын яки аның аерым элементларын, мәдәни мирас объектының тарихи-шәһәр төзелеше тирәлеген саклау белән бәйле булмаган җир казу, төзелеш, мелиоратив һәм башка эшләр башкару;

капиталь төзелеш объектларын һәм аларның өлешләрен төзү һәм һәйкәл территориясендә булган капиталь төзелеш объектларының күләм-киңлек характеристикаларын арттыру;

мәдәни мирас объекты фасадына һәм түбәсенә кондиционерлар, зур габаритлы антенналар һәм инженерлык җиһазларының башка элементларын кую;

мәдәни мирас объектында, шулай ук аның территориясендә тышкы реклама чараларын урнаштыру (мәдәни мирас объектларында, аларның территориясендә мәдәни мирас объектларында, аларның территорияләрендә театр-тамаша, мәдәни-агарту һәм күңел ачу чаралар үткәрү турындагы мәгълүмат тарату яки мәдәни мирас объектында һәм аның территорияләрендә тышкы реклма урнаштыру милекченең яки мәдәни мирас обүюектының башка законлы хуҗасының сак бурычлары таләпләренә туры килгән очракта реклама мәйданының (киңлегенең) ун проценттан артыгын биләмәгән очракта аталган чаралар турында мәгълүмат тарату искәрмә булып тора)

жир өстеннән инженерлык инфраструктурасы объектларын (тышкы суүткәргеч челтәрен, канализация, җылылык, газ һәм электр белән тәэмин итү, телефонлаштыру) үткәрү;

киосклар, павильоннар, өслекләр, кече архитектура формалары кую, юкка чыкканнарын торгызу искәрмә булып тора;

мәдәни мирас объекты һәм аның янәшәсендәге корылмаларга динамик йөкләнеш тудыручы технологияләр файдалану;

мәдәни мирас объекты территориясен теләсә кайсы төрдәге һәм формадагы көнкүреш калдыклары белән чүпләү;

парковкалар оештыру;

мәдәни мирас объектын, мәдәни мирас объектының тарихи элементларын һәм территориясен аларның җимерелү куркынычын тудыручы, мәдәни мирас объектына, шулай ук әйләнә-тирәдәге корылмаларга тискәре йогынты ясаучы куллану төрләрендә файдалану.